**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Исполнительный комитет Чалпинского
сельского поселения
Азнакаевского
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл жирлеге
башкарма комитеты

ул. Центральная, д..35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5--46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» июнь 2017 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Чалпы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, карар бирәм:

1. Чалпы авыл җирлеге Советының 10.02.2014 ел,№ 14 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә (09.09.2016 ел, №38, 28.11.2016 ел, №46 карарлар редакциясендә):

1.1. 27, 28, 29 статьяларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләргә туры китерергә.

1.2. Җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында бүлек эшләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык ____________________ Р.Х.Мәһдиев